Гыйләҗев Т.Ш.
(Казан шәһәре)

**И.Нуруллинның “Моңлы саз чыңнары” әсәрендә Тукай.**

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм әдип И.Нуруллинның күпкырлы һәм киң диапазонлы гыйльми эшчәнлегендә Г.Тукай иҗаты төп урынны алып тора. Ул үзенең бөтен гомерен Г.Тукайга багышлап, бу өлкәдә бертуктаусыз яратып һәм актив эшли. 18 яшендә үз теләге белән сугышка китеп, аның бәла-казаларын үз җилкәсендә татыган, дары исләре иснәгән фронтовик И.Нуруллин 1945 елның җәендә Казан дәүләт университетының тарих-филология факультьтетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң, И.Нуруллин аспирантурага калдырыла һәм Г.Тукайның әдәби – эстетик карашларын тикшерүгә алына.

Гыйльми эшчәнлегендәге тәүге эзләнүләр аңа Тукайның бай шигъри дөньясына ишек ача, һәм И.Нуруллин, XX гасырда Тукай гыйльмиятен үстерүгә, аның офыкларын киңәйтүгә үзеннән зур өлеш кертеп, чын мәгънәсендә тукайчы галим буларак таныла. Шагыйрь һәм аның даирәсе белән бәйле булган материаллар, хатирә - истәлекләр, архив чыганаклары һәм төрле шәкелдәге язмалар белән танышу, И.Нуруллинга, беренчедән, монографик хезмәтләрендә дәлилле, фәнни хөкем йөртергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, аның күңелендә пыскып яткан әдәби иҗат дәртенә ялкын өсти. 1960 елларда И.Нуруллин документаль – биографик жанрдагы әдәби әсәрләр иҗат итүгә керешә. “Тукай Петербургта” (1965) [1] һәм “Тукай турында хикәяләр” (1971) [2] әсәрләрендә шагыйрьнең шәхси тормышыннан алынып, авторның иҗади уйланмасы белән баетылган сурәт-картиналарда Тукайның җанлы һәм якты образы тудырыла, аның шәхси кичерешләре, бәя-хөкемнәре чагыла.

Галимнең бу төр эшчәнлегенең иң югары ноктасы булып әдәби-документаль жанрда язылган “Габдулла Тукай” (1979) [3] исемле китабы тора. Гәрчә әсәрнең язылу вакыты 1974-1976 елларны эченә алса да, ул әдип-галимнең дистә елларга сузылган фидакарь хезмәтенең нәтиҗәсе булып тора.

Бу басмада И.Нуруллин әлеге китапның жанрын тәгаенләүне кирәк дип тапмаган.

Галим Г.Тукайның тормышына, иҗат лабораториясенә караган фактларны эзләү, аларны тулыландыру юнәлешендә эшне дәвам иттерә. 1980 елларның икенче яртысында ил күләмендә башланып киткән демократик үзгәрешләр хезмәтне тагын да тулыландырырга, аерым фактларга һәм мәсьәләләргә яңача карарга мөмкинлекләр ачып җибәрә. Тукай чоры матбугат битләрен актарганда, Г.Исхакый исеменә тап булып, аның кайбер әсәрләре белән дә танышып өлгергән галим шушы атаклы прозаик һәм драматургның әдәби-рухи мирасыннан башка XX йөз башы татар әдәбиятын, Г.Тукай әдәби-мәдәни мохитен бөтен тулылыгында яктырту мөмкин түгеллеген төшенеп, күңеленнән сызланып яшәгән күрәсең. Идеологик кыршау аз гына бушау белән, И.Нуруллин Г.Исхакый исемен һәм аның бай мирасын үз Ватанына, халкына кайтару өчен көрәш башлый. Шушы елларда китапка яңа исемнәр, сәхифәләр өстәлә, һәм аның төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасы, автор үзе вафат булгач, 2000 елда «Моңлы саз чыңнары» [4] исемендә басылып чыга. Инде бу нәшерендә аның жанры документаль роман буларак билгеләнгән.

Дөнья әдәбиятында гына түгел, милли әдәбият тарихында бай тарихы булган бу төрдәге әдәби әсәрләр соңгы еллар әдәбият белемендә зур кызыксыну уятты. Документаль, тарихи, биографик, автобиографик әдәбият, аларның жанр табигате, идея-эстетик сыйфатлары, хосусый үзенчәлекләре тирәсендә әдәби-фәнни бәхәскә нокта куелганы юк [5]. И.Нуруллин әсәрдә Г.Тукай иҗатын XX гасыр башындагы тарихи вакыйгалар һәм иҗтимагый-милли тормыш күренешләре белән тыгыз бәйләнештә яктырта һәм үзенең әдәби-эстетик, фәлсәфи бәясен белдереп бара. Галим-биограф тарафыннан шагыйрь тормышындагы вакыйгалар, әдәби-мәдәни фактларның аның иҗатына тәэсире, йогынтысы анализлап барыла. Безнең карашыбызча, “Моңлы саз чыңнары” әсәре язучының әдәби-фәнни биографиясе жанрында иҗат ителгән, ул үзенең идея эчтәлеге белән шушы форма таләпләренә туры

килә. Автор романда документаль һәм әдәби башлангычларны шагыйрь иҗаты хакындагы бәя-хөкемнәре һәм фәнни карашлары белән үреп синтезлап бара. Алар арасында гармоник ярашу нәтиҗәсендә И.Нуруллин Тукай хакында эстетик һәм тарихи яктан кыйммәтле әсәр тудыруга ирешкән.

Автор бу китапта Тукайның шигъри дөньясын һәм милли әдәбият-мәдәният тарихында тоткан урынын шәрехләүдә элгәре принциплардан, кагыйдәләрдән, методологиядән баш тартмый. Бу факт аның тирән инануы, ышанычы һәм рухи кыйбласының ныклыгы турында сөйли. Мәгълүм булганча, 1950 елларда И.В.Сталинның шәхес культы фаш ителеп, татар әдәбият белеме вульгар социологизм шаукымыннан арынуга йөз тота. 1960-1970 елларда унҗиденче елгы Октябрь борылышыннан соң гыйльми-нәзари фикернең үсеш юнәлешен эзләнүләр чорында марксизм-ленинизм эстетикасы яссылыгында шәрехләнгән тарихи-мәдәни мәктәпнең кагыйдәләренә, матур әдәбиятны шәрехләү принципларына әйләнеп кайтыла. И.Нуруллинның фәнни тикшеренүләрендә, аерым алганда “Моңлы саз чыңнары” романында әлеге тенденция күзәтелә.

Галим, иң беренче нәүбәттә, үз игътибарын Тукайны шәхес һәм шагыйрь буларак формалаштырган иҗтимагый-милли һәм әдәби-мәдәни мохиткә юнәлтә. Татар халкының Тукайгача чорда тупланып киленгән рухи – фикри егәрлегенең, шигъри традицияләренең һәм татар поэзиясенең Тукай иҗатына тәэсире ассызыклана: “[Әмма] Тукай шагыйрь булып танылды. Димәк, ул, барыннан да элек, шигъри традицияләргә игътибар итәргә, шуларга таянырга тиеш иде. Бүтән талантлы шагыйрьләр кебек үк, Тукай да күп кенә бүтән халыкларның поэзиясеннән, әйтик, рус, төрек, билгеле күләмдә гарәп һәм фарсы шагыйрьләреннән үрнәк һәм гыйбрәт алды. Шулай да аның игътибары беренче чиратта үзенең туган поэзиясенә юнәлергә, иҗаты шул туфрактан үсеп чыгарга тиеш иде” [4,61 б.]. Мондый караш шагыйрьнең Җаек чорын бәяләгән сәхифәләрдә тагын да конкретлаша, ассызыклана төшә: “Габдулланың шигъри талантын уяткан, эстетик зәвыгын тәрбияләгән, әдәбиятка карашын калыплаштыруга этәргеч ясаган әдәби

фактлар күп һәм төрле... Әнә шул факторлар Габдулланың шагыйрь булып китүенә мөмкинлек тудыралар. Әмма бу мөмкинлекнең чынлыкка әверелүе өчен, ягъни Габдулланың кулына каләм алып, шигырь яза башлавы өчен ниндидер үрнәк, гыйбрәт, тышкы тәэсир кирәк, икенче төрле әйткәндә, бу талантның әдәби атмосферага эләгүе кирәк иде" [4; 61-62 б.].

Шагыйрьнең рус әдәбиятына тирән мәхәббәте, Пушкин һәм Лермонтов поэзияләренең аның өчен әдәби осталык мәктәбенә әверелүе дә нәкъ шушы төп кагыйдәгә таянып аңлатыла: "Г.Тукайның күңел түрендәге иң беренче, иң кадерле урынны алган Пушкин татар шагыйрен гомер буе озатып барды. Мондый зур мәхәббәтнең тууына Пушкинның диһилыгы һәм рус әдәбиятында тоткан урыныннан кала, Уральск шартлары да күпмедер дәрәҗәдә роль уйнаган. Бөек шагыйрь 1833 елда Җаек каласында булып киткән, шунда җыйган материалларыннан чыгып, "Пугачев тарихы" исемле гыйльми хезмәтен һәм "Капитан кызы" повестен иҗат итә, - дип яза И.Нуруллин һәм конкрет материалга нигезләнгән фаразлау, интуиция ярдәмендә Тукайның, бу еллар тормышын сурәтли. – Габдулла школада өченче кышын укыган вакытта Уральск җәмәгатьчелеге Пушкинның йөз еллыгын киң итеп, зур итеп үткәрергә карар кылган ... Тантанага әзерлек эшләре тегеләйме-болаймы Габдулланың колагына ирешкәндер дип уйларга кирәк. Бакча утырту вакыйгасын, "Пушкин йорты"н ачу тантанасын да аның үз күзе белән күргән булуы бик ихтимал. Бәлки әле, Әхмәтша учитель классны ул тантанага үзе алып баргандыр" [4; 46-47 б.]. Шулай ук рус әдәбияты һәм культурасы тарихында җуелмас эз калдырган А.Н.Плещеев, М.Л.Михайлов, Л.Н.Толстой, В.К.Короленко һ.б.лар Җаек каласында төрле сәбәпләр белән булып киткәннәр. Менә бу фактлар барысы бергә шагыйрь күңелендә рус әдәбияты белән кызыксыну уяткан һәм бай хәзинәгә ишек ачканнар, алдагы көннәрендә шагыйрьлек каләменең куәтләнүенә җирлек әзерләгәннәр.

Күренә ки, автор, мәдәни-тарихи юнәлешнең төп "раса – тирәлек – момент" кагыйдәсендәге һәр буынына нигезләнеп, Тукай иҗатын тикшерә.

Ул шагыйрьнең 1907-1908 еллар иҗатында күзәтелгән сыйфади үзгәрешләрне, матур әдәбият һәм сәнгатьнең татар җәмгыятенең “күзен ачу”, “җәмгыятьтәге әһәмиятле, ләкин кешеләр игътибарыннан читтәрәк калган яки җәмгыять әгъзалары күреп бетерә алмаган киң һәм актуаль мәгънәләрне яктыга чыгару[чы], шулай җәмгыятьне алга, әлеге мәсьәләләрне хәл итәргә чакыру” [6; 86 б.] вазыйфасы ноктасыннан якын килеп, заман, чор сулышы белән сәбәпле бәйләнештә шәрехли: “Инде килеп, заман үзе, җәмгыятьнең барышы, андагы үзгәрешләр Тукайдан шушы ике талантын (лирика һәм сатира – Г.Т.) эшкә җигүне таләп итте. Аңа кадәрге татар поэзиясе, тулаем алганда дидактик характерда булып, лирикага чагыштырмача ярлы иде... Менә 1905 ел давылы шаулап узды. Ул кешенең куәтен, үз язмышын үзе хәл итәргә сәләтле икәнлеген күрсәтте. Әмма кеше азатлык, бәхеткә ирешә алмады. Ник болай? Ник кеше һаман михнәттә, золым астында? Бу хәлдән ничек чыгарга? Борчылу, уйлану, шөбһәләнү,эзләнү. Революция яшененнән күңелендә өмет чаткысы кабынган әнә шул яңа кешенең борчылуны уй-тойгыларын шигърият теле белән әйтеп бирергә кирәк иде” [4; 134 б.].

Алга таба И.Нуруллин Г.Ибраһимов белән Г.Тукай арасындагы катлаулы мөнәсәбәт мәсьәләсенә күчеп, аның сәбәпләре турында уйлана. Чыганаклардан, язмалардан алынган фактларны, бәя-хөкемнәрне төрле принциптан чыгып, төрле үлчәүләргә салып карый. Әдәби бәхәстә ике як тарафыннан дөнья күргән язмалар, полемик ялкын белән бер-берсенә ташланган репликалар, әйтелгән бәя-карашлар җентекләп күздән кичерелә. Автор бу уңайдан әдәбият мәйданында ат уйнаткан ике шәхеснең характер сыйфатларына да туктала. Нәтиҗәдә галим-биограф ике арадагы шәхси, субъектив мөнәсәбәтләрне икенче планга калдырып, бәхәснең төп сәбәбен шагыйрьнең сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге һәм иҗатының халыкчанлыгы белән бәйләп аңлата: “Оек, чабата, ыштыр”ларын да шигъриятькә әвелдерә алган, һәм “бәрәңге көен” көйли торган Тукай баштарак романтизмнан азат булмаса да, тулаем алганда реалист иде. Иҗатының соңгы чорында аның реализмы, романтизмның кайбер уңай сыйфатларын үзенә сеңдереп, яңа

баскычка күтәрелде... Күренә ки, Тукай белән Галимҗан арасындагы бозылышу көнчелек яисә дан бүлешү кебек вак нәрсәдән дә бигрәк, принципиаль мәсьәләдән – поэзиянең асылын һәм иҗтимагый вазыйфасын икесе ике төрле аңлаудан башланган” [4; 252 б.]..

Документаль романда И.Нуруллинның шагыйрь иҗатын бәяләгән катламда Тукайның әдәби-эстетик карашларын тикшерүдә тоткан юлын, мәсләген мәдәни-тарихи юнәлеш рамкасы белән чикләп кую дөрес булмас иде. Мәдәни-тарихи мәктәпнең формалашуына нигез булган биографик метод ысулы Г.Тукайның аерым иҗат чорларын өйрәнүдә И.Нуруллин тарафыннан иркен файдаланыла. Шагыйрьнең нәсел агачыннан аерым буыннар, гомер юлының Кырлай чоры, аеруча Җаек, Казан чоры җентекле рәвештә күздән кичерелә. Мәсәлән, ул Г.Тукайның “Бер мән” исемле шигыреннән иллюстрация китерә дә болай дип яза: “Биредә, һичшиксез”, биография эзе сизелә. Болай да үз тирәсендәге күп кешеләр турында югары фикердә булмаган Тукайга, яраткан бер кешесенең (ихтимал, С.Рәмиевнең. – И.Н.) ниндидер хыянәтеннән соң, күрәсең, бермәлгә бу дөньяда, гомумән, чын кеше юк булып тоелган” [4; 173 б.].

Ә инде шагыйрьнең реакция еллары, ягъни 1908-1910 еллар аралыгындагы күңел җимешләрен анализлаганда, психологик мәктәпнең кагыйдәсенә дә мөрәҗәгать итә һәм бер төркем әсәрләрен, бүгенге татар әдәбият белемендә фәнни әйләнешкә кертелгән модернистик агымның терминын файдаланмаса да, экзистенциализм фәлсәфәсе яссылыгында, яшәү, яшәеш фәлсәфәсе ноктасыннан шәрехли. Шагыйрьнең эчке кичерешләре, җаны, йөрәк тавышы ишетелгән “Катиле нәфескә”, “Өзелгән өмид”, “Газаптан соң”, “Өмидсезлек” шигырьләре шушы дулкында аңлатыла: “Ләкин шул ук көннәрдә Тукай “Тәндә җаным, чык та тәңреңә юнәл, бар, кайт кире!” (ягъни яшәүдән үлем артык. – И.Н.) дип башланган “Өмидсезлек” шигырен яза (“Вакыт” газетасы, 22 май. – И.Н.). Димәк, шагыйрь күңелендә эчке көрәш, ике “мин” тартышы әле дәвам итә. Бер “мин” әйтә: бар да бетте,

өметләр җилгә очты. Икенчесе әйтә: сине халкың үстерде, үз шагыйре итте, сиңа яклаучысы итеп карый, рәхим итеп бурычыңны түлә” [4; 195 б.].

И.Нуруллин шагыйрьнең тәнкыйди-публицистик, сатирик язмаларындагы бәхәсле һәм тенденциоз моментларны, аерым алганда, Г.Тукайның татар халкының әдәбияты һәм мәдәниятендә зур роль уйнаган могътәбәр шәхесләр – И.Гаспралы, М.Бигиев, Р.Фәхретдинов, Ф.Кәрими, Һ.Максуди, С.Максудиларга, “Вакыт”, “Йолдыз”га кебек газеталарга төрле рухтагы тәнкыйди мөнәсәбәтен әйләнеп узмый. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, мондый урынсыз, ялгыш тәнкыйтьнең сәбәпләрен автор Г.Тукайның характер сыйфаты, инкыйлаби-демократик позициясе, чор үзенчәлеге белән бәйләп аңлата.

Шулай итеп, И.Нуруллин татар халык шагыйре Г.Тукай шәхесен, аның кыска, әмма бай тормышын, хисси – эмоциональ, образлы чагылдыру юнәлешендә милли әдәбият тарихында үзгә сукмагын булдыра. Ул “Моңлы саз чыңнары” китабында галим, биограф һәм әдип буларак чыгыш ясый. Шуның белән Тукай әдәби осталыгының, үлемсез шигъриятнең серләренә укучыны төшендерә.

Әдәбият:


1. Нуруллин И. Тукай Петербургта / И.Нуруллин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 92 б.
2. Нуруллин И. Тукай турында хикәяләр / И.Нуруллин. – Казан: Таткнигоиздат., 1956. – 135 б.
3. Нуруллин И. Габдулла Тукай / И.Нуруллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 304 б.
4. Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: Документаль роман. Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма / И.Нуруллин. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.
5. Холиков А.А. Биография писателя как жанр. Учебное пособие / А.А. Холиков. – М.: Книжный дом “ЛИБРОКОМ”, 2000. – 96 с.; Малкина В.Я. Поэтика исторического романа. Проблема инварианта и типология жанра / В.Я.Малкина. – Тверь: Твер.гос.ун-т, 2002. – 140 с. и др.
6. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.